СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 1-34 от «24» сентября 2024 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының «Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды турында» 2011 елның 15 апрелендәге 3-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварендәге № 7-ФЗ Федераль законы, Мамадыш муниципаль районы Советының 2011 елның 15 апрелендәге «Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды турында» 3-5 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2011 елның 15 апрелендәге 3-5 номерлы карары белән расланган «Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды» Уставына (алга таба – Фонд Уставы) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Фонд Уставының 2.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-муниципаль районның инфраструктурасын, инженерлык-коммуникация тәэмин итүен киңәйтүгә ярдәм итү.».

2. Мамадыш муниципаль районы Советының 2011 елның 15 апрелендәге №3-5 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы социаль-икътисадый үсеш фондының Попечительләр Советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Попечительләр Советы Фонды составыннан түбәндәгеләрне чыгарырга:

- Садриева Минзилә Миннәхмәт кызы, «Мамадыш туган якны өйрәнү музее» МБУ директоры – Попечительләр советы әгъзасы.

000099

2.2. Попечительләр Советы Фонды составына кертергә:

- Давыдова Гөләндәм Гарәфетдин кызы, «Мамадыш туган якны өйрәнү музее» МБУ фәнни хезмәткәре – Попечительләр советы әгъзасы.

3. Фонд Уставына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Фонд Уставына күрсәтелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен кирәкле барлык документларны әзерләүне Татарстан Республикасы буенча Россиянең 18 нче районара Фонд башкарма директоры Салахов Салих Гасыйм улына йөкләргә.

4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Мамадыш муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Р.Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгы — В.И.Никитин